ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№426 от «16» 12 2020 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 25 июлендәге 202 номерлы карарына (06.05.2020 ел, № 173 карарындагы үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү турында

Мамадыш районы прокуратурасының 2020 елның 10 ноябрендәге 02-08-03-2020 номерлы күрсәтмәсе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы «Торак урынны, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану турындагы нигезләмәне раслау хакында» 47 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 25 июлендәге 202 номерлы карары (06.05.2020 ел, № 173 карарындагы үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш районы территориясендә бинаны, торак урынны, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт, торак йортны бакча йорты дип тану буенча ведомствоара комиссия турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 1.4. пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

Комиссия составына региональ торак күзәтчелеген (муниципаль торак контролен) уздыруга вәкаләтле санитар эпидемиологик, янгын, экологик һәм башка иминлек, кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәләрендә дәүләт контроле һәм күзәтчелеге, шулай ук, кирәк булган очракта, шул исәптән гадәттән тыш хәл зонасы чикләрендә урнашкан объектларның (торак биналарның) җыелма исемлеге нигезендә урыннар тикшерелгән очракта, архитектура, шәһәр төзелеше органнары һәм тиешле оешмалар вәкилләре, билгеләнгән тәртиптә проект документациясенә һәм (яисә) инженер эзләнүләре нәтиҗәләренә экспертиза бәяләмәләрен әзерләү хокукына аттестацияләнгән экспертлар кертелә.

Торак урын милекчесе (ул вәкаләт биргән зат) комиссиядә киңәш бирү тавышы хокукына ия, эшкә җәлеп ителә һәм аңа комиссия утырышы вакыты һәм урыны турында хәбәр ителергә тиеш.

0000010735

Гадәттән тыш хәл аркасында зыян күргән торак урын милекчесенең комиссия эшендә катнашу тәртибе Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының аерым карары белән билгеләнә.

1.2. 1.8 пунктта “язмача” сүзләреннән соң түбәндәге эчтәлекле сүзне өстәргә: Комиссия составына кертелгән очракта, әлеге Нигезләмәнең 1.4 пунктында күрсәтелгән затларның торак урынын тикшерүдә катнашырга.
1.3. Нигезләмәнең 1.10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2.Комиссия утырышы Рәис яисә аның урынбасары тарафыннан чакырыла һәм комиссия утырышында, аның әгъзаларының гомуми санынннан кимендә яртысыннан артыграгы, шул исәптән дәүләт күзәтчелеге (контроле) органнары, архитектура һәм шәһәр төзелеше органнары һәм тиешле оешмалар вәкилләре, комиссия составына кертелгән экспертлар катнашса, карар кабул итәргә хокуклы (кворум бар).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары вазифаларын башкаручы Р. Р. Хаҗиевка йөкләргә.

Җитәкче                                                                                    И.М.Дәржеманов